■ Йәшләргә нәсихәт

# ЙӘШЛӘРГӘ

Дилә БУЛГАКОВА

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим.**

Картәтиләребез, нәнәйләребез, әти-әниләребез дога белән тормышка аяк басканнар, өйләнгәннәр, тормышлы булганнар... Безне алар догалар белән үстергәннәр. Дога безгә яшәгәндә дә, үлгәндә дә кирәк.

Аллаһ Тәгаләгә шөкер, хәзер укысак китапларыбыз бар, мәчетләребез бар! "Собханаллаһ!" дип сокланып, укырга, өйрәнергә. Тирән белем бирүче дин әһелләребез, мөгаллимнәребез бар! Иренмә, вакыт табып мәчетләргә бар, Аллаһ йортының ишекләре ачык! Соң түгел, укы, өйрән, намазга бас! Шөкер кыла бел! Әлхәмдүлилләһ, мәчетләребез хәзер һәр бер авылда диярлек. Уңган, егәрле ир-егетләребез, аксакалларыбыз мәчетләр салалар, динебез тарала - куанып шөкер кылырга кирәк...

...Кулымда - нәнәм дисбесе,
Дога - телемдә.
Өстәлемдә - ризык тулы,
Әлхәмдүлилләһ!
Биш вакыт намаз укыгач
Бәхетле кем дә!
Яшимен иманлы булып,
Әлхәмдүлилләһ!

**Зөфаф кичәсендә кияүнең кәләше янына кергәндәге дога**

Зөфаф кичәсе - яшь егетнең тормышында, иң мөһим бер кичәдер. Гаиләсенең нигезен, башлангычын ничек корса, шул рәвештә дәвам итәр. Бу караштан мөселман егет никахын һәм туен гореф-гадәтләргә туры китереп үткәрергә һәм Зөфаф кичәсендә, ике рәкәгать намаз кылып, бәхетле булулары өчен Аллаһка дога иткәннән соң, "Бисмиллаһ" әйтеп, шушы доганы укыр: "Раббәнәә һәбләнәә мин әзвәҗинәә вә зурриийәәтинәә курратә әгъйүниү үәҗгәлнә лилмүттәкыйнә имәәмә" ("Фуркан" сүрәсе, 74нче аять). (Әй, Раббыбыз! Безгә хатыннарыбыздан һәм нәселләребездән күзләребезнең нуры, сөенече булырлык яхшы кешеләр бүләк ит һәм безне тәкъва ияләренә хуҗа кыл).

Аять укыганнан соң, кәләше белән бергә булудан элек "Бисмиллаһ" әйтер һәм дога укыр: "Әллааһүммә җәннибиәттәйтанә вә җәннибиш-шәйтанә мә разәкотәнә" (Аллаһның исеме белән, Аллаһым! Шайтанны бездән һәм безгә бүләк итәчәк баладан ерак кыл) (Бохари, Никах, 66).

Дөнья матур, җитез булса да, хәзер күп яшьләр, бер күрүдә бер берсенә карата туган җылы хисләрне, олы мәхәббәтемне очыраттым дип, икенче көнне үк җитәкләп алып кайта да, бергә тора башлыйлар.

Шуңа тормышлары бармый, тауыш-гауга түрләрендә утыра һәм сабыйлары гарип, яисә чирле булып доньяга туа! Аңламасың күп яшьләрне. Ата-анасының фатихасын алмаган күп гаиләләр бәхетле түгел, аерылыша, арада күпме әрнүле, үкенүле күз яшьләре тама...

Ә менә бигерәк тә соңгы елларда игелекле, изгелекле уңган ир-егетләребез Аллаһ йорты - мәчетләр салалар. Никахлар белән яшьләребез кавыша. Әлхәмдүлилләһ! Күз тимәсен безнең мәчетләребезгә. Күпме белемле яшьләр дин юлында.

Сокланырлык - сансыз хатын-кызларыбыз яулык бәйләп арабызда йөриләр, үзләре тыйнак, тәртипле сөйкемле. Йөзләреннән нур бөркелә.

■ Илхам



### НИКАХ УКЫДЫ ИМАМ

Азан чакыра намазга,
Моң тарала тоташтан.
Манараның көмеш ае
Гүя күккә тоташкан.

Мәчетнең ишеге ачык,
Аллаһ йорты - түрдән уз!
Бисмилласын әйтеп керде
Егет белән асыл кыз.

Сылу кызый, асыл егет,
Икеседә мөселман!
Оялганлык йөзләрендә,
Калебләрендә иман.

Күзләренә бу доньяның
Бар гүзәллеге сыйган.
Собханаллаһ, бу яшьләргә
Никах укыды имам.

Мәчетнең ишеге ачык,
Тоташкан келәм җәйгән.
Килсен кызлар ак яулыктан,
Егетләр түбәтәйдән!

### КИЛЕН

Никахтан соң яулык бәйләп,
Атладың тупсам аша.
Ак яулыгың - ак күлмәгең
Буй сыныңа килешә.

Намазында ак яулыктан
Нәнәңнәр дога кылган.
Теләкләре изге булгач,
Иншаллаһ, кабул булган.

Ят караштан, яман сүздән,
Тайпыл, балам, узып үт!
Тартынмыйча горур йөре,
Син мөселман кызы бит.

Оялчанлык, сабырлыгың -
Сөрмә тарткан күзеңдә,
Нурын өсти ак яулыгың,
Сөйкемле ак йөзеңә.

Тартынмыйча яулык бәйлә,
Озын күлмәгең тылсым!
Сеңелләргә, яшь кызларга
Үрнәк булырлык булсын.

Озын күлмәк, ак яулыгың,
Килен, сиңа килешә.
Түбәйтәйле улым белән
Атладың тупсам аша.

Башыңа кара яулыклар
Язмасын, юк, бәйләргә.
Чәчкәлесен сайлап кына,
Бәйлә син бәйрәмнәрдә.

Дилә БУЛГАКОВА.

### Пәйгамбәребезнең соңгы вәгазе

Бу хөтбә милядтан соң 632 елда Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) тарафыннан йөз меңнән артык мөселман каршында укылган. Аллаһы Тәгаләгә мактау һәм олылау сүзләреннән соң Пәйгамбәребез әлеге хөтбәне укыган.

- Әй, кешеләр! Сүземне яхшы тыңлагыз. Белмим, бәлки быелдан соң сезнең белән биредә мәңге күрешә алмабыз. Кешеләр! Бу көннәрегез һәм айларыгыз, бу шәһәрегез (Мәккә) нинди мөбарәк булса, җаннарыгыз да, малларыгыз да шулай ук мөкатдәстер, чөнки алар һәртөрле начарлыктан сакланган.

Иптәшләрем! Бер көн килер, һәм сез Раббыгыз белән кавышачаксыз. Ул көндә һәр хәл һәм кылган эшләрегез өчен һичшиксез җавап бирәчәксез. Зинһар, миннән соң да элекке азгынлыкларга кайтып, бер-берегезгә зыян китермәгез! Бу васыятемне монда булганнарыгыз да яхшырак аңларлар, сүземнән чыкмаслар. Иптәшләрем! Кемнең кемгәдер әманәте булса, ул аны иясенә тапшырсын. Мин сезгә һәртөрле фаизны тыйдым, аяк астына салып таптадым. Ләкин сез төп бурычларыгызны үтәгез. Беркемгә дә золым ясамагыз, үзегез дә золымга дучар булмассыз. Моннан соң Аллаһы Тәгаләнең әмере белән фаизчылык тыелды. Исламга кадәр булган бу ямьсез гадәтләр аяк астына салып тапталды. Иң беренче булып бетерелгән фаиз абыем Габелмоталлипның улы Габбасныкы булды.

Иптәшләрем! Исламга кадәр булган дәвердән килгән кан үче бөтенләй бетерелде. Мин тыйган беренче кан үче абыем Габделмоталлипның оныгы Рабианыкы булды.

***(Дәвамы бар).***

# Күңел җылылыгын җәлләмик

Камилә НАСЫРОВА

И, тылчымлы сүзләр!

Бар икән бит алар дөньяда, бар! Бер карасаң, гади генә алар, кай-берләре хәтта берничә хәрефтән торса да, ягъни бик кечкәй генә булсалар да, кайгыга, төшенкелеккә баткан кешеләрнең күңелләрен генә түгел, тормышларын, дөньяга карашларын да гүзәл бер борылыш белән яктылыкка, якшылыкка борып җибәрү көченә ия икән бит!

Һәр кешенең гомере - искиткеч, сокландыргыч бер мизгел. Кая гына бармый да, ниләр генә күрми ул. Һәм һәрберсе үзенчәлекле, бер-берсенә охшамаган кешеләр белән без көн саен күрешәбез, алар - тирә-ягыбызда. Бер үк юл тузанын тапасалар да, бер үк йортта яшәсәләр дә, бер үк әти-әни балалары - ягъни игезәкләр булсалар да - алар барыбер төрлечәләр, - бу Аллаһ Тәгаләдән булган хикмәтләрнең кечкенәсе.

Безне хәйран калдырырлык нәрсәләр тирә-ягыбызда, безнең белән алар гел бергә. Урамнан барам... Күпме кеше! Күпме кабатланмас әзләр! Кабатланмас уйлар, хәрәкәтләр! Кай-берләре моңсу, кайберләре көләч йөзле, яисә уйчан. Үзләре юлда булсалар да, уйлары белән кайда гына барып чыкмыйлардыр инде алар!

Әнә, олы яшьтәге бер апа авыр сумкасын сөйрәп җәфалана. Уе бер генә - нинди бәлаләр белән булса да - урынына итеп җиткерү. Һәм шундый ярдәмгә мохтаҗ кешеләр адым саен, диярлек. Елмаеп карыйк, дустым, кешеләрнең йөзенә, ягымлы сүзләр белән хәлен сорашыйк һәм әз генә ярдәм кулын сузыйк. Син шунда ук сизерсең, күрерсең аның да елмайганын, мең рәхмәтләр әйткәнен. Аптырарлык. Артык әллә ни көч тә кирәкми, авыр түгел икән бит кешенең күңелен күтәрү, көнен чагу буяуларга буяу. Ә инде ул кеше тагын да башка берәр кешегә ярдәм кулы тәъкдим итсә, яхшылык, яктылык әз генә булса да артачактыр, диеп уйлыйм. Әйе, дөнья авыр, көннәр шулай бертөрле, соры төстә... Ләкин безнең максат - Аллаһ Тәгаләнең ризалыгында булу. Ул кушканнарны үтәүгә бер адым ясасак икән. Беренче адым һәр вакыт авыр. Тирә-якны, кешеләр дөньясын үзгәртү үзебезне үзгәртүдән башлана. Чөнки нинди генә матур сүзләр сөйләсәк тә, нинди генә нәфис сүз остасы булсак та, әгәр дә сөйләгәнне үзебез эшләмибез икән, барыбер максатның киресе булачак. Шуның өчен, дустым, башлыйк үзебездән. Уйламыйк, безнең хәлебез башка кешеләрнекенән начарррактыр да әле, диеп. Без бу хәлләргә әз генә булса да өстәнрәк карыйк: бездән дә мөшкелрәк яшәгәннәр дә байтак, шуңа күрә шөкер итик, һәм бездән ярдәм өмет иткәннәр янына ашыгыйк.

Бел син, безнең яндагы кешеләр - безнең кебек үк гаҗиз җан! Күр, ул да ярдәмгә мохтаҗ. Сузыйк ярдәм кулын, җәлләмичә җылы сүзебезне, якты йөзебезне һәм шундук сизәрбез аның да елмаюын, күңеле күтәрелүен. Бездән булган ярдәм кешедә күп нәрсәне үзгәртә, үзебезне хәтта аңардан да бәхетле тоя башлыйбыз, шатлыклар әчкә сыймый.

Шулай, кечкәй генә мәрхәмәтлелек орлыгын сал син аның йөрәгенә, курма, корыр диеп, без бит тик сәбәпче генә, Аллаһ насыйп итсә инде ул бүген шытып үсеп чыгачак, ә иртәгә инде бар тирә якны сокландырып чәчкә атачак. Бәлки күп кешенең күңлен үзгәртә алырдай хуш ис бөркәчәк!..

Чынлап та, безнең кечкенә сүзләребез дә, әз генә булса эшләгән яхшылыгыбыз да - үзебезгә барбер зураеп, кубәеп кайтачак. Чөнки без нинди генә теләк теләсәк, сүзләр әйтсәк, изгелекләр кылсак та, хәтта начарлык эшләсәк тә - фәрештәләр һәр вакыт - сиңа да шулай ук, сиңа да шулай ук, диеп торалар. Ә аларның теләгәннәрен кабул итәчәк Аллаһ Тәгалә, Иншаллаһ!

Раббым! Ач Син күңелләребезне, йөрәкләребездә булган каралыктан арынырга ярдәм ит! Син риза булырдай эшләр эшләп, тирә-якка тик изгелек күзлеге аша гына карарга насыйп ит! Ихластан ит ниятләребезне, уйларыбызны.

Аллаһым! Без Синең ярдәмеңә һәрвакыт мохтаҗ, Бар эшләгән эшләребез Синең ризалыгың өчен булса икән, ярдәмеңнән аерма, Аллаһ!

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Йомадиәл әүүәл 2010 миләди йыл**
**1431 һижри йыл.**

| Рабиғүл ахыр, Йомадиәл әүүәл | Аҙна көндәре | Апрель Май | Иртәнге намаҙ | Ҡояш ҡалҡа | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. намаҙы | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 29 | Шаршамбы | 14 | 5.47 | 7.17 | 14.30 | 19.48 | 21.18 | 22.48 |
| 1 | Кесе йома | 15 | 5.45 | 7.15 | 14.30 | 19.50 | 21.20 | 22.50. |
| 2 | Йома | 16 | 5.42 | 7.12 | 14.30 | 19.51 | 21.21 | 22.51 |
| 3 | Шәмбе | 17 | 5.40 | 7.10 | 14.30 | 19.53 | 21.23 | 22.53 |
| 4 | Йәкшәмбе | 18 | 5.37 | 7.07 | 14.30 | 19.55 | 21.25 | 22.55 |
| 5 | Дүшәмбе | 19 | 5.35 | 7.05 | 14.30 | 19.57 | 21.27 | 22.57 |
| 6 | Шишәмбе | 20 | 5.33 | 7.03 | 14.30 | 19.59 | 21.29 | 22.59 |
| 7 | Шаршамбы | 21 | 5.30 | 7.00 | 14.30 | 20.01 | 21.31 | 23.01 |
| 8 | Кесе йома | 22 | 5.28 | 6.58 | 14.30 | 20.03 | 21.33 | 23.03 |
| 9 | Йома | 23 | 5.26 | 6.56 | 14.30 | 20.05 | 21.35 | 23.05 |
| 10 | Шәмбе | 24 | 5.23 | 6.53 | 14.30 | 20.07 | 21.37 | 23.07 |
| 11 | Йәкшәмбе | 25 | 5.21 | 6.51 | 14.30 | 20.09 | 21.39 | 23.09 |
| 12 | Дүшәмбе | 26 | 5.19 | 6.49 | 14.30 | 20.11 | 21.41 | 23.11 |
| 13 | Шишәмбе | 27 | 5.17 | 6.47 | 14.30 | 20.13 | 21.43 | 23.13 |
| 14 | Шаршамбы | 28 | 5.14 | 6.44 | 14.30 | 20.15 | 21.45 | 23.15 |
| 15 | Кесе йома | 29 | 5.12 | 6.42 | 14.30 | 20.16 | 21.46 | 23.16 |
| 16 | Йома | 30 | 5.10 | 6.40 | 14.30 | 20.18 | 21.48 | 23.18 |
| 17 | Шәмбе | 1 | 5.08 | 6.38 | 14.30 | 20.20 | 21.50 | 23.20 |
| 18 | Йәкшәмбе | 2 | 5.06 | 6.36 | 14.30 | 20.22 | 21.52 | 23.22 |
| 19 | Дүшәмбе | 3 | 5.04 | 6.34 | 14.30 | 20.24 | 21.54 | 23.24 |
| 20 | Шишәмбе | 4 | 5.02 | 6.32 | 14.30 | 20.26 | 21.56 | 23.26 |
| 21 | Шаршамбы | 5 | 5.00 | 6.30 | 14.30 | 20.28 | 21.58 | 23.28 |
| 22 | Кесе йома | 6 | 4.57 | 6.27 | 14.30 | 20.30 | 22.00 | 23.30 |
| 23 | Йома | 7 | 4.55 | 6.25 | 14.30 | 20.32 | 22.02 | 23.32 |
| 24 | Шәмбе | 8 | 4.53 | 6.23 | 14.30 | 20.33 | 22.03 | 23.33 |
| 25 | Йәкшәмбе | 9 | 4.52 | 6.22 | 14.30 | 20.35 | 22.05 | 23.35 |
| 26 | Дүшәмбе | 10 | 4.50 | 6.20 | 14.30 | 20.37 | 22.07 | 23.37 |
| 27 | Шишәмбе | 11 | 4.48 | 6.18 | 14.30 | 20.39 | 22.09 | 23.39 |
| 28 | Шаршамбы | 12 | 4.46 | 6.16 | 14.30 | 20.41 | 22.11 | 23.41 |
| 29 | Кесе йома | 13 | 4.44 | 6.14 | 14.30 | 20.43 | 22.13 | 23.43 |
| 30 | Йома | 14 | 4.42 | 6.12 | 14.30 | 20.44 | 22.14 | 23.44 |